РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МИХАЙЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИХАЙЛОВКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423975, Р.Т. Муслюмовский район, с. Михайловка, ул. Гагарина,д.24
Mih.Mus@tatar.ru тел. (8-85556) 3-62-32

*с.Михайловка* *« 15 » 03 2019г.*

**КАРАР № 5**

**Михайловка авыл җирлеге Мөслим муниципаль районы
2019 елгы язгы ташу чорында халыкны һәм территорияләрне яклау чаралары турында**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Михайловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 7 статьясы нигезендә, 2019 елгы язгы ташу чорында халыкны кисәтү һәм яклау, хуҗалык һәм торак объектларын, гидротехник корылмаларны, юлларны һәм күперләрне саклау максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хөкүмәте Документлар ТР Хөкүмәте карарлары ТР Хөкүмәте карарлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елгы язгы ташу чорында Михайловка авыл җирлеге халкын һәм территорияләрен яклау чаралары планын 1 нче кушымта итеп расларга.
2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге икътисад объектларының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләрен тәкъдим итәргә:
- КЧСПБ утырышларында, авыл җирлегенең кризиска каршы комиссиясе утырышларында язгы ташу суларын авариясез уздырып җибәрүне тәэмин итү мәсьәләләрен карарга;
– язгы ташу күренешләре аркасында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләргә реакция ясау һәм авария-торгызу эшләрен үткәрүгә җәлеп ителә торган көч һәм чаралар группировкасын төгәлләштерүне оештырырга. Көч һәм чаралар турында мәгълүматларны җыю һәм гомумиләштерү, аларның гамәлләрен контрольдә тотуны оештыру, язгы ташуга каршы чаралар оештыруны тәэмин итү;
- язгы ташуның тискәре нәтиҗәләреннән халыкны һәм территорияләрне саклау буенча чаралар үткәрелүен контрольдә тотуны тәэмин итәргә;
3. Мөслим муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиягә «ташу» планын тормышка ашыру турында мәгълүматларны 23.03.2019 елга кадәр тапшырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Башкарма Комитет Җитәкчесе
Михайловка авыл җирлеге башлыгы Р. Х. Исламов.

1 нче кушымта

Башкарма комитет житәкчесе
карарына
от 15.03.2019ел. №5

2019 елгы язгы ташу чорында Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау буенча чаралар планы.

| № | Чаралар исемлеге | Башкару вакыты | |
|---|---|---|---|
| 1 | 2019 елгы язгы ташуга әзерлек мәсьәләсе буенча утырыш үткәрү. | 16.03.2019 | Башкарма комитет житәкчесе |
| 2 | Гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм бетерү буенча оператив планны корректировкалау, авыл жирлеге территориясендә язгы ташу күренешләре белән бәйле гадәттән тыш хәл нәтиҗәләрен бетерү, аны үтәү өчен җәлеп ителә торган көч һәм чаралар оештыру. | 18.03.2019 | Башкарма комитет житәкчесе |
| 3 | Юллар торышы, юлсызлык булганда, керү юлларына контроль оештыру, яр буйларынв "бозга керергә ярамый" дигән билге кую. | Су басу чоры дәвамында | Башкарма комитет житәкчесе |
| 4 | Михайловка авыл жирлеге территориясендә урнашкан оешма, учреждение житәкчеләре белән гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда кагыйдәләр турында әңгәмә үткәрергә | 18.03.2019 кадәр | Башкарма комитет житәкчесе |
| 5 | Авыл жирлеге чикләрендә гражданнарның жыеннары үткәрү юлы белән яшәү урыны буенча гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда, шәхси әңгәмәләр үткәрү кагыйдәләрен халыкка житкерү. Михайловка авыл жирлеге сайтында, гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда кагыйдәләр турында мәгълүмати стендлар урнаштыру. | Ташу чоры башланганчы | Башкарма комитет житәкчесе, мәктәп директоры, мәдәният йорты, ФАП. |
| 6 | Су басу куркынычы булган зонага кергән торак биналардан һәм корылмалардан кар суы юллары ачу эшләрен оештыру. | Су басу чоры дәвамында | Башкарма комитет житәкчесе, шәхси йорт хужалары. |
| 7 | Язгы ташу чорында зыян күргән кешеләргә медицина ярдәмен күрсәтүне оештыру буенча әзерлек эшләре үткәрү. | Су басу чоры дәвамында | Башкарма комитет, үзәк хастаханә, с/п территориясендәге ФАП |

Башкарма Комитет Җитәкчесе
Михайловка авыл җирлеге башлыгы Р. Х. Исламов